**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 22 февраль | № 112

г. Казань

Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбе счетларының бердәм планын һәм аны куллану буенча инструкцияне раслау турында» 2010 елның 1 декабрендәге 157н номерлы боерыгының 28 нче пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт милкендә булган мөлкәтне исәпкә алуны камилләштерү һәм аның белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\112.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 112 нче карары белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЗНАСЫН ТӘШКИЛ ИТКӘН ОБЪЕКТЛАРНЫ (ФИНАНС БУЛМАГАН АКТИВЛАРНЫ) ЯҢАДАН БӘЯЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбе счетларының бердәм планын һәм аны куллану буенча инструкцияне раслау турында» 2010 елның 1 декабрендәге 157н номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

2. Тәртиптә, Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) (алга таба – Объектлар (финанс булмаган активлар)) бюджет исәбендә күрсәтү максатларында, аларны яңадан бәяләүне үткәрү кагыйдәләре билгеләнә.

3. Объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү операцияне башкарган көнгә, шулай ук бюджет хисаплылыгын төзүнең хисап датасына гамәлгә ашырыла.

4. Күчмә мөлкәткә кергән Объектларны (финанс булмаган активларны) (алга таба – күчмә мөлкәт) яңадан бәяләү Объектның (финанс булмаган активның) баланс кыйммәтен һәм амортизация суммасын үзгәртмичә башкарыла. Шул ук вакытта баланс кыйммәте билгеләнмәгән күчмә мөлкәтне яңадан бәяләү бюджет исәбендә беренчел кыйммәтне шартлы бәяләүдә: бер объект, бер сум дип күрсәтеп гамәлгә ашырыла.

5. Күчемсез мөлкәткә кергән Объектларны (финанс булмаган активларны) (җир кишәрлекләреннән тыш) (алга таба – күчемсез мөлкәт объектлары) яңадан бәяләү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

эксплуатациядә 20 елдан артык булган яисә эксплуатациягә кертү елы билгеләнмәгән күчемсез мөлкәт объектларын яңадан бәяләү күчемсез мөлкәт объектының яңадан бәяләү көненә кадастр кыйммәтен билгеләү юлы белән башкарыла. Җыелган амортизация суммасы линияле ысул белән аерым исәпләнә;

эксплуатациядә 20 елдан азрак булган яисә кадастр исәбенә куелмаган һәм кадастр кыйммәте булмаган күчемсез мөлкәт объектларын яңадан бәяләү баланс кыйммәтен һәм амортизация суммасын үзгәртмичә башкарыла. Шул ук вакытта баланс кыйммәте билгеләнмәгән күчемсез мөлкәтне яңадан бәяләү бюджет исәбендә беренчел кыйммәтне шартлы бәяләүдә: бер объект, бер сум дип күрсәтеп гамәлгә ашырыла.

6. Объектлар (финанс булмаган активлар) составына керә торган җир кишәрлекләрен яңадан бәяләү җир кишәрлекләренең яңадан бәяләү көненә кадастр кыйммәтен билгеләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

7. Яңадан бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы карары белән раслана һәм Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте реестрына кертелә.

8. Объектлар (финанс булмаган активлар) белән операцияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте реестрындагы мәгълүмат нигезендә бюджет исәбендә чагылыш таба.